| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОИШТЕРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 27 сентябре** **№ 22**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә,2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

«2019 елда Яңа Иштирәк авыл җирлеге чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән һәр граждандан 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

тапшырылган вәкаләтләр нигезендә торак пунктның суүткәрү милкен карап тоту;

зиратны карап тоту;

Урамнарны яктыртуны оештыру

« Әйе Юк».

2. Әлеге карарны Яңа Иштирәк авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре»

бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Яңа Иштирәк авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе Г.Р.Мәүлетова